ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Гражданнарның гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуына бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү турында» 480-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.К. Хамаев, Т.Г. Һадиев тарафыннан кертелгән «Гражданнарның гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуына бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү турында» 480-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2023 елның 26 октябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты 2023 елның 2 ноябренә кадәр әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 19 октябре
№ 2184-VI ДС

проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
А.К. Хамаев, Т.Г. Һадиев
тарафыннан кертелә

**«Гражданнарның гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуына бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү турында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Гражданнарның гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуына бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 3 ноябрендәге Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 3 өлешенә (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2021, № 93 (I өлеш), «Җирле үзидарә органнары» сүзләрен «Муниципаль районнарның, шәһәр округларының җирле үзидарә органнары» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Гражданнарның гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуына бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы закон проектына**

**АҢЛАТМА**

«Гражданнарның гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуына бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты республика законын «Гараж берләшмәләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 24 июлендәге 338-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә федераль законнарга туры китерү максатларында әзерләнде.

Әлеге Федераль закон белән «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 5 апрелендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертелде һәм муниципаль районнар җирле үзидарә органнарының Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында хокуклар теркәлмәгән гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә карата кадастр эшләрен яисә комплекслы кадастр эшләрен башкаруны тәэмин итү хокукы беркетелде. Шуның белән бергә җирлекләр җирле үзидарә органнарының әлеге эшләрне башкаруны тәэмин итү хокукы турында нигезләмә төшереп калдырылды.

Федераль законнардагы бу үзгәрешләрне «Гражданнарның гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуына бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 3 ноябрендәге Татарстан Республикасы Законында чагылдырырга кирәк.

**«Гражданнарның гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуына бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Гражданнарның гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуына бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, аларга үзгәрешләр кертүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Гражданнарның гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуына бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Гражданнарның гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуына бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.